| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**27.12.2024** № **04-05-133**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 10 ноябрендә 04-05-105 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карарны Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитеты тарафыннан кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 10 ноябрендә 04-05-105 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2024 елның 10 сентябрендәге 04-05-96 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карарны Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитеты тарафыннан кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

4.1 пунктчада «Хисаплылыктан өземтәләр» сүзләрен «Белешмәләр» сүзенә алмаштырырга;

4.2 пунктчаны «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160[1] статьясы нигезендә билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча Дәүләт комитетының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган» сүзләре белән тулыландырырга;

4.3 пунктчада:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында акт яки бюджет керемнәре администраторы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд акты, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә (Тәртипнең 2 пунктының 2.5 пунктчасында күрсәтелгән очракта);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«гражданның судтан тыш банкротлык процедурасын тәмамлау турында Банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ (Тәртипнең 2 пунктының 2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракта).».

Рәис М.Г.Зиатдинов